


ISSN 0868-4545

Салават күпере



Бәйрәм бәйгесе

Бәйрәм бүген,бәйрәм бүген, дип язган шагыйрь. Әйе, чынлап та бәйрәм. Бүген генә түгел... бәйрәмнәр еш була.

Синең уйлап караганың бармы? «Бәйрәм» сүзе каян килеп чыкты икән ул, ә? Бәйрәм булгач, чәчәкләр дә күп була бит инде. Бәйләм-бәйләм була алар. Бәлкем, «бәйләм» сүзеннән килеп тә чыккандыр әле. Әлбәттә, бу – шаярту. Эш сүздә генә түгел. Мәсьәлә аның мәгънәсендә, асылында.

Әти-әниең сине кочаклап сөйсәләр дә бәйрәм була. Август аенда уздырыла торган «Шәһәр көне» дә – зур бәйрәм. Бакчада сине тәрбияче апаң мактаса да, бәйрәм инде. Мәктәптән «биш»ле алып кайтсаң, тагын зур бәйрәм. Кыскасы, кеше тормышында бәйрәмнәр гаҗәеп күп.

Синең өчен тагын нинди вакыйгалар бәйрәм? Әйдәгез, «Бәйрәмнәр бәйгесе» оештырып җибәрик әле. Ә син безгә шул турыда хат яз, яме.

«Салават күпере».



Рәссам Алла АЙСИНА

© "Салават күпере", 2004 ел

Тәбикмәк

Син, Камилә, камыр бас,
Син табаны тот ипләп.
Дәү әнине тәбрикләп,
Пешерәбез тәбикмәк.

Тукай да тумаган

Борын-борын заманда
Шүрәле булмаган, ди,
Кәҗә дә булмаган, ди,
Сарык та булмаган, ди,
Әкиятләр язарга
Тукай да тумаган, ди.

Фәрит БӘДРЕТДИНОВ, 9 яшь.
Казан

Җәяүле хат

Борын-борын заманда,
Машинасыз чакларда,
Җәяү йөргән атлар да,
Җәяү йөргән хатлар да.

Бүре — кунак

Кунакка чакырдым
Бүре белән Куянны.
Куян килмәде.
Уйлагандыр:
«Кишер куярмы?»
Кыяр бирдем,
Бүре ашамады кыярны.
Ул Куянны көтте.
Арып бетте.
Көтә-көтә туйды.
Мине ашады да куйды.

Шамил МУЛЛАХМӘТОВ,
8 яшь. Арча.




Хуҗа һәм бай

Бервакыт Хуҗа Насретдин, бер бай белән өенә кайтып барганда, бай 99 сум акча тапкан.

Хуҗа байга:

– Ташла аны, 100 сумга да тулмагач, нигә алырга. Мин 100 сумга бер генә тиен тулмаса да, алмас идем, – дигән.

Икенче көнне бай, Хуҗаны сынау өчен, бер янчыкка 99 сум акча салып, Хуҗаның ишегалдына ташлаган. Үзе яшеренеп Хуҗаны күзәтеп торган. Хуҗа өеннән чыккан да, янчык белән акчаны алып, санап кесәсенә салган. Бай моны күреп:



– Хуҗа әфәнде, нигә аласың, акча 100 сумга тулмый бит! – дигән.

Хуҗа кесәсендәге янчыкны яңадан кулына алып әйләндергәләп караган да:

– Акчасы 99 сум булса, янчыгы бер сум тора, – дип китеп барган.

Рәссам
Илдар НӘФИЕВ

Ишәк өстендә

Хуҗа ишәгенә атланып базарга китеп барганда, аның артыннан ат менгән бер бай килеп җиткән. Ул, Хуҗаны хурламакчы булып:

– Йә, ишәк өстендә бару ничек, әйбәтме? – дип сораган.

– Атка атланган ишәккә караганда, акыллы баш булып, ишәккә атланып йөрү күңеллерәк, – дип җавап кайтарган Хуҗа.



Хуҗа байны кәкре каенга терәткән

Бервакыт Хуҗа зыяраттагы каен агачына сөялеп тора икән. Хуҗа янына бер бай килеп:

– Йә Хуҗа, мине бер алдап кара әле, – дигән.

– Алдавын алдар идем дә бит, алдар капчыгым өйдә калган, – дип җавап кайтарган Хуҗа.

– Бар, алдар капчыгыңны алып кил, – дигән бай.

– Килүен килер идем дә, менә бу каенны терәп торырга кирәк, югыйсә ул ава, – дигән Хуҗа.

– Бар, алып кил, үзем терәп торырмын, – дигән бай.

– Кара аны, аударасы булма, югыйсә аударып мәетләрне куркытырсың, – дигән Хуҗа. Шуннан соң Хуҗа өенә киткән дә, ятып йоклаган. Бай бер сәгать көткән, ике, өч, дүрт, биш сәгать буена каенны терәп торган. Ахырда түзмәгән, кинәт кузгалып киткән һәм куркуыннан аяклары җиргә тияр-тимәс йөгергән. Байтак киткәч, артына борылып караса, ни күзе белән күрсен, каен аву түгел, селкенми дә икән. Шунда гына бай үзенең бик нык алданганлыгын аңлаган.



БӘЙГЕ ТӘМАМ! БӘЙГЕ ДӘВАМ ИТӘ!

КОНКУРС!

Казан шәһәренең 1000 еллыгына багышлана

«Дию пәрие Казанны алырга килә»

«Салават күпере»ндә без «Дию пәрие Казанны алырга килә» дигән әкияти бәйге игълан иткән идек. Ошбу бәйгегә йомгак та (апрель аенда) ясалды һәм җиңүчеләр дә игълан ителде. Вәгъдә ителгәнчә, 1 нче урынга дигән велосипедны (Арча, Яңа Кенәр, Айгөл Вәлиева), 2 нче урынны яулаган укучыга үзе йомшак, үзе бик зур филне (Балтач, Таузар, Гөлүсә Габдрахманова) тапшырдык. Һәм 3 нче урынияләренә (Сарман, Җәлил, Гөлназ Абзалова, Зөлфинә Газизова) матур китаплар җибәрдек.


Әлеге бәйге Казан шәһәренең 1000 еллыгына багышланган иде. Тагын нәкъ бер елдан, киләсе елның август аенда, Казаныбызның юбилее була. Һәм без әлеге бәйгене тагын дәвам итәргә уйладык. Димәк, бәйге дәвам итә. Хатлар сездән, ә бүләкләр — бездән. Без вәгъдәбездә тора беләбез, дәлил итеп сезгә җиңүчеләрнең фоторәсемен тәкъдим итәбез.

Бәйгенең шартларын журналыбызның былтыргы 8-9нчы санынннан укый аласыз.

Бәйгедә катнашырга теләгән һәр укучы «Салават күпере»нә язылган булырга тиеш.

Димәк, башладык! Хәерле сәгатьтә!

«Салават күпере».



Александр ЭШКИНИН фотосы.



Карак песи



Яшәгән ди, булган ди бер әби белән бабай. Булган ди аларның ике песиләре: Каракай һәм Сарыкай. Каракай ялкау һәм хәйләкәр булган, ә Сарыкай, киресенчә, акыллы, эшчән һәм бик юмарт. Каракай көннәр буе йокы симерткән: тычканнар тотасы урынга, әби белән бабайның келәтеннән каймак, казылык урлап, шуларны ашап, мич башында көннәр буе ята икән. Әби белән бабай келәткә кереп ризыкларның юкка чыгуына аптырыйлар ди. Кем урлый икән аларны? Кем безнең өйдә карак? Шушы сорауларга җавап таба алмыйча, әби белән бабай тынычлана алмаганнар.

Беркөнне хәйләкәр Каракай (ул Сарыкай белән дус булмаган) келәттән урлаган тәмле әйберләрне Сарыкай йоклый торган урынга яшереп куя. Әби белән бабай тәмле әйберләрне Сарыкай урынында табып, аны бик каты ачуланалар. Сарыкайны капчыкка салып, урманга алып барып, шунда калдыралар.

Ә Каракай, өйдә бер үзе калып, хәйләкәрлеген дәвам итә биргән. Әби белән бабай бөтенләй аптыраганнар. Инде карак песине дә урманга илттек, ә келәттән ризыкларны барыбер кемдер ташый. Вәт аптыраш!!!

Безнең әйберләрне, күрәсең, тычканнар урлыйлар. Шулай дип уйлап, әби белән бабай келәткә тычкан тота торган капкын куйганнар. Икенче көнне капкынны тикшерер өчен келәткә керсәләр, ни күз белән күрсеннәр, капкынга аларның яраткан Каракайлары эләккән. Менә кем икән монда карак! Ә без Сарыкайны бер гаепсезгә ачуланып кара урманга илттек. Бу юлы әби белән бабай Каракайны урманга илткәннәр. Сарыкайны эзләп табып, чын карак песине аның урынына калдырганнар. Өйгә кайткач Сарыкайдан гафу үтенгәннәр, аңа тәмле ризыклар ашатып, аны сыйпап җылы мич башына йокларга яткырганнар.

Шуннан бирле әби белән бабайның өйләрендә тынычлык урнашкан. Келәттән дә әйбер урлаучы юк ди, тычканнар да азынмый ди.

Йосыф БИКЧӘНТӘЕВ, 10 яшь.
Казан (4 нче мәктәп).

Мәче рәсемен Яшел Үзән районы, Олы Ачасыр авылыннан **Миләүшә ЗӘЙНУЛЛИНА** (9 яшь) ясап җибәрде.

Ил ГАФИ

Актүш белән Акмаңгай

Акмаңгай. Һалло! Һалло! Актүш, синме бу?

Актүш. Һалло! Мин тыңлыйм. Син кем?

Акмаңгай. Мин Акмаңгай. Исәнме, Актүш?

Актүш. Мин сине белмим. Сиңа кем кирәк?

Акмаңгай. Без бит синең белән бертуган. Оныттыңмыни? Әни сине Шамилгә, мине Камиләгә бирде. Без Камилә белән дуслар, мин аның белән уйныйм. Ул мине ярата. Минем үз туганым белән дә уйныйсым килә. Әйдә, урамга чыгабыз!

Актүш. Минем уйныйсым килми. Шамил мине кыйнады.

Акмаңгай. Әллә үзең гаеплеме?

Актүш. Юк. Ни генә кушсалар да, мин тыңлыйм ич.

Акмаңгай. Аның өчен кыйнамыйлар.

Актүш. Әнисе Шамилне ачуланды. «Әнә Актүштән үрнәк ал!» – диде. Моңа Шамилнең ачуы килде дә мине кыйнады.

Акмаңгай. Икебез дә тыңлаучан булгач, Камиләне дә, мине дә тиргәмиләр.

Актүш. Акмаңгай, әнине күрсәң, әйт әле, ул мине Шамилдән алып, синең яныңа илтсен.

Акмаңгай. Ярый, Актүш, елама, без сине коткарырбыз...





Ни өчен Динәне бал корты чакмаган?

Динә белән Айгөл урманга җиләккә барганнар. Динә бик тырышып, тып-тын гына йөргән, бик күп җиләк тапкан. Ә Айгөл кычкырып-бакырып, чәчәкләрне таптап узган. Чәчәктән-чәчәккә кунып, бал җыеп йөрүче бал кортларының бик ачуы килгән. Берсе Айгөлнең башына кунып, чагыйм микән, юк микән дип, чәч арасында «без»ләп йөргән. Айгөл чәчләрен йолкып кычкырган, чәбәләнеп бөтен урманны яңгыраткан. Менә шул чак бал корты аны чаккан да куйган.

Бал кортының икенчесе Динәнең дә башына кунган. Динә кычкырмаган да, чәчләрен дә туздырмаган. Бал корты аны чакмаган. Савыты җиләк белән тулган кызны бал кортлары «тагын килегезз!» дип, өенә кадәр озата барганнар.

Айгөл буш кәрзинен ташлап, өенә елап кайткан...

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ




Данил, 5 ай

– Юктан гына үпкәләштек,
Икәү калгачтын өйдә.
Маймылкаем, җанкаем,
Дуслашыйк инде әйдә!

Казан.




Владик, 9 ай


– Ник син бер дә сөйләшмисең,
«Һау-һау!» гына дисең гел.
Телең юкмы әллә, дигәннән,
Бар икән ич: о-озын тел!

Казан.


Диләрә, 7 яшь

– Энҗе-мәрҗән, алтын акча
Килми әзергә-бәзер.
«Пират кыз» идем мин әүвәл,
Принцесса мин хәзер!

Түбән Кама.


Алсу һәм Данил

– Кәнфит бир инде, абый, дип
Күпме ялвардым сорап.
Абый аркамны чеметте –
Шуңа мин
Утырам еламсырап.

Казан.

Җәйнең матурлыгына тагын бер кат сокланыйк әле.





Румия Идрисова, 12 яшь.
Буа, Кайбыч.



Зөлфирә Гыйльманова, 11 яшь.



Сөмбел Хәйдәршина, 5 яшь.
Мамадыш, Югары Берсут.



Алия Мөхәсимова, 8 яшь.
Зәй, Карман.



Рәмзия Фәсәхова, 5 яшь.
Минзәлә.



Мансур Мәзнәвиев, 9 яшь.
Актаныш, Иске Богады.



Шаһинур МОСТАФИН

Ватанымның бер таңы...

Төн. Тирә-як тынлыкка чумган – кешеләр дә, кошлар да, агачлар да йоклый. Без дустым Рәфгать белән черкиләргә каршы көрәшә-көрәшә учак янында утырабыз. Икебез дә сөйләшмибез, күккә һаман да көчлерәк үрелгән ялкын телләренә карап, уйга чумганбыз...

Уйларыбыздан аерырга теләгәндәй, якындагы авылдан беренче әтәч кычкырганы ишетелә. Төнге тынлыкта бу тавыш музыка булып яңгырый. Аңа башка әтәчләр кушылалар.

– Тиздән таң ата! – дип куйды дустым...

Төн, әтәч музыкасыннан курыккандай, җир өстенә япкан кара япмасын тиз-тиз генә җыя башлый – аның артыннан сөңге нурлары белән кояшлы көн куып килә бит!

Таң – искиткеч гүзәл. Аны күрергә теләп, гөлләр йокыларыннан уяналар, бу матурлыктан хисләнеп, күз яшьләрен-чыкларын коялар. Сандугачлар бу гүзәллекне мактап яңа көйләр иҗат итәргә керешәләр. Һәр таң – яңа көй ул!

– Их, матур да соң дөнья, рәхәт тә соң яшәве!! – дип куйдык икебез дә.

Елга өстендәге ак томан, шушы яңа көйдән аерыласы килмәгәндәй, әкрен генә тарала башлый...

Таң атканны күзәтергә теләгәндәй, балыклар сикерешә, уйнаша. Әнә, җим эзләргә чыккан кызылканатны иптәшем эләктереп тә алды. Балык: «Мин әле яшәүдән туймадым», – дигәндәй, тыпырчынды. Без аны кире җибәрдек.

Яңа көн тууын хәбәр итеп, йомшак таң җилләре ак алъяпкычлы каен кызларына, сыгылма билле яшь талларга кагылып үттеләр. «Уяныгыз, шушы гүзәллекне күрегез, янәсе». Кап-кара күзле карлыганнар көнгә елмаялар. Алсу иренле бөрлегәннәр һәм баланнар таң нурында тагы да матуррак балкыйлар...

Кояш һаман да югарыга таба тәгәри...

Әнә, печәнчеләрнең аш-су остасы да болынлыкта мәш килә. Ул, төне буе янып чыгып, хәзер инде сүнеп барган учагын яңадан тергезергә тели, аңа кайнар сулышын өрә. Учак, яңа көнне исән-сау каршы алуына шатлангандай, дөрләп китте. Ул да яңа көнгә үзенең яктылыгын һәм җылылыгын өстәргә тели иде булса кирәк...

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ



Равил ФӘЙЗУЛЛИН

Тау

Газиз белән тотынышып,
икәү тауга менәбез.
Менгән саен, Туган якның
киңлекләрен күрәбез.

Адым саен без үсәбез,
ә тау – тәбәнәгәя...
Менә-менә башларыбыз
болытка тимәгәе!

Безнең күләгәләр төшә
кошларның канатына.
Утырганбыздыр шикелле
хыялның ак атына!

Уенчык күк өстән – йортлар,
күлләр, поезд юллары...
Ә без гүя әкияттәге
Алып батыр уллары!

Газиз белән тотынышып,
икәү таудан төшәбез.
Аяк асларына карап,
таштан ташка күчәбез.

Арттан тау зураеп кала.
Кошлар очалар өстән.
Күләгәбез, кечерәеп,
аяк астына күчкән.

Тылсымлы кебек күренми
сукмак та, тирә-юнь дә.
Газиз арып, кунаклады –
әтисенең иңендә!

Ә шулай да, күңелләр шат.
Өйдә – әни, алда – юл.
Тауларга менгән кешеләр
Кечерәя алмый ул!



Нәҗибә САФИНА

Икәү

– Хәзер кибеткә барабыз.
– Әни, икәүме?
– Хәзер шоколад алабыз.
– Әни, икәүме?
– Хәзер без аны ашыйбыз.
– Әни, икәүме?
Бу бит бик кечкенә, әни,
Миңа җитәрме?

Булмый...

Их!
Сиңа берне,
Миңа берне.
Алмалары
Бигрәк эре!

Их!
Эреләр һәм
Пешкәннәр!
Их, өзелеп
Төшсеннәр!

Их!
Үртәп тора:
«Өз! — диеп, —
Буең җитми,
Түз», — диеп.

Их!
Алманы өзеп
Булмый...
Их!
Өзми дә
Түзеп булмый...
...Их!



Яшел алкалы курчак

Яшел алка усакта,
Усакта.
Яфрак сорый
Курчак та:
«Миңа яшел
Алка, — ди, —
Алып бирче,
апа», — ди.
Яфракны өзим микән...
Өзмичә
Түзим микән...

«И-и, — дидем, —
Кайгырмачы!»
Алдым да кәгазь,
Кайчы,
Ясадым
Шундый алка!
«Күрдеңме? — дим
Усакка, —
Алка такты
Курчак та...»

Рәссам Диләрә НӘҮРУЗОВА



Факил САФИН

КЫЗЫК

Соңгы вакытта Айгөлне ишек алдына бик чыгармаска тырышалар. Әле әтәч талый диләр, әле ата каз дип куркыталар. Чебиләр, каз бәбкәләре анда, Айгөлнең аларны бик тә күрәсе, кулына тотып карыйсы, алар белән уйныйсы килә. Ә үзен генә чыгармыйлар, үзе генә булмагач, аксыл йомгак чебиләрне дә, сары йомшак бибиләрне дә кулга алып булмый инде ул.

Бүген аңа уйнап керергә рөхсәт иттеләр. Әнисе өй җыештыра, Айгөлнең җиң сызганып чиләккә табан килүен күргәч, аны уйнап керергә чыгарып җибәрде.

Койма буендагы челтәр тәрәзле читлектә чебиләр ярма бөртекләре чемченеп йөргән булалар. Аларны читлектән бик чыгарыр иде Айгөл, ишек келәсенә буе җитми. Ярый, челтәр тәрәздән карап торсаң да кызык икән.

Ул арада бакча артыннан кайтып килүче Мәликә әбисе күренде. Алъяпкычы итәген кайтарып тоткан. Айгөлнең күргәне бар, әбисе чебиләргә үлән йолкып алып кайта шулай. Алып кайткан үләнне ләгәнгә салды да, Айгөлгә һичнигә кагылмаска кушып, нәрсәдер алып чыгарга өйгә кереп китте әби. Айгөлгә шул гына кирәк тә. Ничек инде кулга тотып карамый түзәсең үләннәрне. Кызыктыра бит.

Эре, тере яфраклы үләнне бер дә күргәне юк иде Айгөлнең. Сокланудан йөзенә яктылык җәелде. Тиз генә барып, бер бәйләм үләнне кулына алган иде, нәни бармакларын су пешекләп алдымыни! Яндыра, әчеттерә. Айгөл чыр итеп кычкырып елап җибәрде.

Ишектән берьюлы диярлек әнисе белән әбисе йөгереп килеп чыктылар.

– Ни булды тагын? – диде әнисе куркынган тавыш белән.

– Әтәч явыз кетәклектән чыкмагандыр бит? – диде әбисе. – Югыйсә ныклап ябып куйган идем...

Айгөл әрнегән кулын өскә күтәрде.

– Ай-ай... – дип такмаклады ул. – Авырта-а...

– Кычыткан бәласе икән бу, – диде әбисе хәлгә төшенеп. – Әйттем. Бернәрсәгә дә кагылма, дидем...

– Кычытмый, авырта-а, – дип үксүен белде Айгөл.

– Кычыткан...

Әбисе сүзен әйтеп бетермәде, Айгөл тагын да ныграк үкси башлады:

– Кычытмый, авырта-а...

– Аңладым, аңладым, – диде әбисе, көлемсерәп. «Өф-өф» итеп кызчыкның бармагына өреп алган иде, бармакның әрнеп сулкылдавы басыла төште:

– Менә бу тешләде... – диде Айгөл, әбисенә сыенган килеш эре яфраклы үләнгә ачулы карап.

– Бу үлән – кычыткан дип атала да инде, кызым. Тешләми ул, чага. Мин яшь кычытканнарны бакча артыннан алып кайтам да, чебиләргә турап бирәм. Яраталар аны наныйлар. Кычытканны ашагач, алар авырмый, тиз үсәләр. Менә шундый бик файдалы үсемлек булгач, аны өзеп алучылар да күп була. Ул үзенә кагылган кешеләрне куркытам дип, чагып ала.

Әбисе файдалы дип бик мактаса да, Айгөл кычытканга яңадан кагылмаска булды. Үсә бирсен койма буенда. Әбисе белән дуслашканнардыр алар, аны бер дә чакмыйлар ич.



Рәссам Светлана ПРИВИНА

Башваткычлар



Рәссам Илдар НӘФИЕВ

Бер-берсенә охшаган ике күбәләкне табыгыз.



Алар да сөя белә...

Үз тарихы бар бу китапның. Һәм ул тарих «Таһир-Зөһрә» газетасы белән бәйләнгән. Әлеге газетаның беренче санында ук очерк басылган иде. Минтимер Шәрипович белән Сәкинә Шакировна яшь чакта ничек табышканнар, гаилә төзеп җибәреп, ни рәвешле яшәп киткәннәр? Шул сорауларга җавап иде анда.

Шулай ук Һ.Такташ, Г.Кутуй кебек классикларыбызның, Г.Бәширов, А.Гыйләҗев, Г.Ахунов кебек олугларыбызның (үзләре исән чакта, үз куллары белән яздылар) мәхәббәт һәм тормыш кыйссаларын халыкка җиткердек.

Еллар уза торды. «Таһир-Зөһрә»нең һәр санында диярлек урын алып барган мондый мәкалә-очерклар нәкъ бер том булып җыелган икән! Һәм менә, озак уйлап тормастан, без аларны сезгә китап итеп тәкъдим итәбез.

Зиннур Хөснияр,
«Ак Барс» нәшрият йорты директоры.

Сәхнә журналын укысагыз, яраткан артистларыгызның тормыш, иҗат юлы белән танышып торырсыз, сәхнә артындагы мәзәк хәлләрдән дә хәбәрдар булырсыз.
Индексы – 16852.

Әлеге журналга Татарстанның һәм Рәсәйнең теләсә кайсы элемтә бүлекчәсендә язылырга мөмкин.

Салават күпере

8(173) — 2004

ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ: ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЖИР, МИЛЕК МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ ҺӘМ РЕДАКЦИЯ КОЛЛЕКТИВЫ.
1990 елның март аеннан бирле чыга.

УЧРЕДИТЕЛИ: МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РТ, ПРАВЛЕНИЕ СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ РТ И КОЛЛЕКТИВ РЕДАКЦИИ.
Основан в 1990 году.
На татарском языке.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде.

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары
Вакыйф НУРИЕВ

Җаваплы сәркатип
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Фидель ХӘСӘНОВ

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта Фәридә ХАСЬЯНОВА рәсеме.

Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен.


Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.
E-mail: ck-sxn@newmail.ru

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм тесләргә бүленде.

«Идел-пресс» полиграфия нешрият комплексы» дәүләт унитар предприятиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Производствога бирелде 8.07.2004 ел.
Басарга кул куелды 8.07.2004 ел.
Кәгазь форматы 60х100 1/8.
Гарнитура – Прагматика.
Офсет ысулы белән басылд.
Тиражы 9017 данә. Заказ Э-496.

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953



Нәкыйп КАШТАНОВ

Август

Кырларны һаман уйлап,
Чормада ята урак.
Болытлар йөри урап.
Кырларда йөри кораб.
Яңа икмәк сала оста.
Кайсы айда?
Августта.

